**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 20 ноябрь № 881

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетның кайбер актарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 25 май, 411 нче карарының 1 нче пункты үз көчен югалткан дип санау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасында алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияләр биргән өчен юридик затларның җыемга түләү чыгымнарын өлешчә каплауга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2009 ел, 5 август, 538 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияләр биргән өчен юридик затларның җыемга түләү чыгымнарын өлешчә каплауга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2009 ел, 5 август, 538 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 25 март, 221 нче.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетның кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел, 25 май, 411 нче карарының 1 нче пункты үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\881.docx